**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул. Советская, д.80,**
**с. Новошешминск,423190**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**Совет урамы, 80,**
**Яңа Чишмә авылы,423190**

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районыСоветы
КАРАРЫ

2021 елның 19 мартыннан № 7-50

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2009 елның 27 маендагы 34-228 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль торак булмаган фондын арендага бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль мөлкәт белән идарә итү һәм аның белән эш итү системасын камилләштерү, аны арендага бирү шартларында файдалану нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан, 2018 елның 4 июнендәге 135-ФЗ номерлы «Конкуренцияне яклау турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2009 елның 27 маендагы 34-228 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль торак булмаган фондын арендага бирү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

5.1 пунктның 12 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында» 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үткәрелгән конкурс яки аукцион нәтиҗәләре буенча дәүләт яисә муниципаль контракт төзелгән затка, әгәр әлеге хокукларны тапшыру конкурс документларында, әлеге дәүләт яисә муниципаль контрактны үтәү максатларында аукцион турында документларда каралса, яки «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында»2011 елның 18 июлендәге 233-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үткәрелгән конкурс яки аукцион нәтиҗәләре буенча дәүләт яисә муниципаль автоном учреждение белән килешү төзелгән затка бу мөлкәткә аренда хокукын бирү. Мондый мөлкәткә хокукларны бирү срогы дәүләт яисә муниципаль контрактны яисә шартнамәне үтәү срогыннан артмаска тиеш.

2.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында»http://pravo.tatarstan.ru,Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы В.М.Козлов